ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10. 08. 2021 г.Мензелинск № 277

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын 2021-2022 уку елына әзерләү турында

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы мәгариф учреждениеләрен яңа 2021-2022 уку елына оешкан һәм вакытында әзерләү, белем бирү хезмәтләренең сыйфатын күтәрү, аларның һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү максатында, Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында белем бирү учреждениеләрен 2021-2022 уку елына әзерләү буенча ведомствоара комиссия төзергә һәм аның кушымта итеп бирелә торган составын расларга.
2. Минзәлә муниципаль районы МКУ «Мәгариф бүлеге»

- белем бирү учреждениеләренең яңа 2021-2022 уку елына әзерлеген кабул итү буенча комиссия төзергә (1 нче кушымта);

-белем бирү учреждениеләрен яңа уку елы башлануга һәм кышкы чорда эшләүгә вакытында һәм сыйфатлы әзерләүне оештырырга, террорчылыкка каршы, янгын һәм санитар-эпидемиологик куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүгә аерым игътибар бирергә.;

- уку елы дәвамында белем бирү учреждениеләре укучыларын һәм персоналын шартлы эвакуацияләү буенча өйрәнүләр үткәрүне тәэмин итәргә;;

- гамәлдәге закон таләпләре нигезендә мәктәп автобусларында укучыларны йөртү иминлеген тәэмин итү буенча барлык кирәкле чараларны күрергә;

- яңа уку елы башлану мәсьәләләре буенча халык белән мәгълүмати бәйләнешне тәэмин итү;

- 2021 елның 26 августына кадәр район мәгариф учреждениеләренең яңа 2021-2022 уку елына әзерлеген кабул итү эшләрен төгәлләргә.

3. МКУ«Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» һәм МКУ«Мәдәният бүлеге» Минзәлә муниципаль районы өстәмә белем бирү учреждениеләренең яңа 2021-2022 уку елына әзерлеген кабул итү буенча комиссия төзергә;
4. Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Г. Бикеевага әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә. йөкләргә.

Җитәкче К. Р. Нәҗмиев

1 нче кушымта
Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитеты
Карарына
№ 277 10.08.2021 ел

СОСТАВ
белем бирү учреждениеләрен 2020-2021 уку елына әзерләү турында
ТР Минзәлә муниципаль районы ведомствоара комиссиясе
.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Бикеева Н.Г. | | Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары-комиссия рәисе |
| **Комиссия әгъзалары:** | | | |
| 2. | Петраев Л.В. | | МКУ «Мәгариф бүлеге »җитәкчесе-комиссия рәисе урынбасары |
| 3. | Тимерханов А. Ф. | | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Актаныш һәм Минзәлә муниципаль районнары буенча надзор эшләр һәм профилактик эшләр районара бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| 4. | Бариев И. Г. | | Татарстан Республикасы буенча Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсенең Чаллы шәһәрендәге, Актаныш, Тукай, Мөслим, Минзәлә районнарында территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча). |
| 5. | Кәримов Р. Г. | | «Минзәлә АТП» ҖЧҖ директоры (килешү буенча); |
| 6. | Исхаков И. И. | | Россия Эчке эшләр министрлыгының Минзәлә муниципаль районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| 7. | Габдрахманов Р. К | | "Минзәлә районы коммуналь челтәрләре" АҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| 8. | Солтанов Р. Р. | | Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы «капиталь төзелеш идарәсе " МУП директоры (килешү буенча) |
| 9. | Хизбуллин Ф. Г. | | МКУ «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» җитәкчесе |
| 10. | Галиева Р. М. | | Минзәлә муниципаль районы «мәдәният бүлеге » МКУ җитәкчесе |
| 11. | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) | | |